| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.10.2021 с.Старое Дрожжаное № 446

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Халыкара автомобиль йөртүләрен гамәлгә ашыруга дәүләт контроле һәм аларны үтәү тәртибен бозган өчен җаваплылык турында «Федераль законның 2 һәм 6 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 02 июлендәге 337 номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 23 сентябрендәге 548 номерлы карары (2018 елның 16 мартындагы 124, 04.07.2018 № 345 редакциясендә) белән расланган "Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында"гы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**2.1 пунктының 12 пунктчасына** «даими рәвештә пассажирлар йөртү халыкара маршрутларыннан тыш» сүзләре белән;

**2.1 пунктының 13 пунктчасы** «даими пассажирлар йөртү халыкара маршрутларыннан тыш» сүзләре белән;

**10.2 пунктының беренче абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

10.2. Муниципаль, муниципальара, чиктәш төбәкара, төбәкара маршрутлар реестрларына түбәндәге белешмәләр кертелергә тиеш:»;

**12.7 пунктында** «Транспорт чараларының резерв саны» сүзләреннән соң «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны даими йөртүне оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында «Федераль

законның 28_1 статьясындагы 1 һәм 1_1 өлешләрендә күрсәтелгән»,» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И. С. Бикчуровка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д.А. Сатдинов